КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2018 ел, 31 октябрь | г.Казань | № 971

Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген билгеле бер куркынычлык категориясенә кертү критерийләрен раслау турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген билгеле бер куркынычлык категориясенә кертү критерийләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 31 октябрь, 971 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген билгеле бер куркынычлык категориясенә кертү критерийләре

1. Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тоту Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләү турында» 2014 елның 28 октябрендәге 1110 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

2. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләү контролен гамәлгә ашырганда куркынычка йөз тоткан якын килүне куллану максатында юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркынычка йөз тоткан якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 17 август, 806 нчы карары белән расланган Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар файдалана торган җитештерү объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә яки куркынычның билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре һәм әлеге критерийләр нигезендә куркынычның билгеле бер категориясенә кертелергә тиеш.

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркынычлык категорияләренә кертү, федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру өлкәсендәге мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан үтәмәүнең мөмкин булган тискәре нәтиҗәләре авырлыгын исәпкә алып, куркынычлык күрсәткечләре һәм юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан  мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеге күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләр үтәмәүнең мөмкин булган тискәре нәтиҗәләре авырлыгын исәпкә алып куркынычлык һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан  мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеге күрсәткече 1 таблицада китерелгән критерийләр нигезендә билгеләнә.

Таблица 1

Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген билгеле бер куркынычлык категориясенә кертү критерийләре

| Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тоту объектлары | Куркынычлык категорияләре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Мәҗбүри таләпләр үтәмәүнең мөмкин булган тискәре нәтиҗәләре авырлыгы һәм мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеге критерийләре | |
| 1. 2, 3, 4 пунктларда каралган шартлар булмаганда күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге | түбән куркыныч |
| 2. Йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз файдалану һәм карап тоту өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр:<br>юридик зат яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркынычлык категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә кадәр соңгы өч елда законлы көченә кергән Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 9.23 ст. 1, 2, 4 өл. каралган административ хокук бозаган өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки шәхси эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында карар булганда;<br>юридик зат яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркынычлык категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә кадәр соңгы өч елда законлы көченә кергән Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 9.23 ст. 5,5 өл. каралган административ хокук бозулар өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки шәхси эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында суд карары булганда | югары куркыныч |
| 3. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген | сизелерлек куркыныч |

| 1 | 2 |
|---|---|
| гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр:<br>юридик зат яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркынычлык категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә кадәр соңгы өч елда законлы көченә кергән Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 7.23 ст.; 7.23.2 ст. 1 өл.; 9.5.1 ст.1, 2, 3 өл.; 9.16 ст. 4, 5, 12 өл., 13.19.2 ст. 1 өл. каралган административ хокук бозаган өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки шәхси эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында карар булганда;<br>юридик зат яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркынычлык категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә кадәр соңгы өч елда законлы көченә кергән Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 7.23.2 ст. 2 өл.; 7.23.3 ст.; 7.23.2 ст.; 14.1.3 ст. 19.4 ст.1 өл., 19,5 ст., 1, 24 өл; 19.6 ст.; 19.7 ст.; 19.7.11 ст. каралган административ хокук бозаган өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки шәхси эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында суд карары булганда | |
| 4. Юридик зат яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркынычлык категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә кадәр соңгы өч елда планлы тикшерүләр үткәргәндә административ җаваплылыкка тартылу белән бәйле булмаган мәҗбүри таләпләрне бозулар билгеле булган күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр | уртача куркыныч |

3. Критерийләр нигезендә гамәлгә ашыра тоган эшчәнлекләренә бирелгән куркынычлылык категориясенә бәйле юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерүләр түбәндәге вакыттан вакытка кабатлана:

югары куркынычлылык категориясе өчен – елга бер тапкырдан күп түгел;

сизелерлек куркынычлылык категориясе өчен – ике елга бер тапкырдан күп түгел;

уртача куркынычлылык категориясе өчен – өч елга бер тапкырдан күп түгел;

түбән куркынычлылык категориясе өчен – дүрт елга бер тапкырдан күп түгел.

4. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр гамәлгә ашыра торган эшчәнлекне куркынычлылык категорияләренә кертү һәм аны куркынычлылык категорияләренең берсенә кертү турында карарны яңадан карау ел саен, агымдагы елның 1 августына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы (башлык урынбасары) карары белән гамәлгә ашырыла.

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр гамәлгә ашыра торган эшчәнлекне

куркынычлылык категорияләренең берсенә кертү турында карар булмаганда юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге түбән куркынычлылык категориясенә кертелгән дип санала.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе эшчәнлекләренә куркынычлылык категориясе бирелгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр исемлеген (алга таба – Исемлек) алып бара.

Эшчәнлекләренә куркынычлылык категориясе бирелгән юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне Исемлеккә кертү Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгының (башлык урынбасарының) алар эшчәнлеген карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә тиешле категориягә кертү турында карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Исемлек түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) куркынычлылык категориясе бирелгән юридик затның тулы исеме;

б) төп дәүләт теркәү саны;

в) салым түләүченең индивидуаль саны;

г) юридик затның урнашу урыны;

д) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр гамәлгә ашыра торган эшчәнлеккә куркынычлылык категориясе бирү турында карар реквизитлары, куркынычлылык категориясенә күрсәтмә, шулай ук алар нигезендә карар кабул ителгән мәгълүматлар.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында югары куркынычлылык категориясенә кертелгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштырыла һәм актуальләштерелә, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

а) югары куркынычлылык категориясе бирелгән юридик затның тулы исеме;

б) төп дәүләт теркәү саны;

в) салым түләүченең индивидуаль саны;

г) югары куркынычлылык категориясе бирелгән юридик затның урнашу урыны;

д) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр гамәлгә ашыра торган эшчәнлеккә куркынычлылык категориясе бирү турында карар реквизитлары, куркынычлылык категориясенә күрсәтмә, шулай ук алар нигезендә карар кабул ителгән мәгълүматлар.

Мәгълүматны урнаштыру дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

7. Юридик зат, шәхси эшмәкәр элек бирелгән куркынычлылык категориясен үзгәртү турында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә гариза бирергә хокуклы.

8. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе ел саен, агымдагы елның 1 августына кадәр юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр гамәлгә ашыра торган эшчәнлеккә элек бирелгән куркынычлылык категориясен карап тикшерүне гамәлгә ашыра.

---